**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№1** **07.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге составына керүче,
Якты-Күл авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 08 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2020 елда, Үчәлле авыл җирлеге Якты-Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Якты-Күл авылы Якты-Күл урамы буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Якты-Күл авылы территориясен куаклардан, чүп үләннәреннән чистарту һәм тоташ гербицид белән химик эшкәртү;
- Якты-Күл авылында юлларны кардан чистарту;
- Якты - Күл авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Якты - Күл авылында («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел") бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Якты - Күл авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Якты - Күл авылында ике телдә урам күрсәткечләрен һәм торак йортлар өчен номерларны сатып алу (әзерләү).
- Якты- Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы урнаштыру (материал сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Якты - Күл авылында Бөек Ватан сугышы ветераннары стендын бизәү.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 54 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 40 кеше

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 40 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге составына керүче Якты - Күл авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2020 елда, Үчәлле авыл җирлеге Якты-Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Якты-Күл авылы Якты-Күл урамы буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Якты-Күл авылы территориясен куаклардан, чүп үләннәреннән чистарту һәм тоташ гербицид белән химик эшкәртү;

- Якты-Күл авылында юлларны кардан чистарту;

- Якты - Күл авылында җәйге чорда территорияне чабу;

- Якты - Күл авылында («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел") бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;

- Якты - Күл авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Якты - Күл авылында ике телдә урам күрсәткечләрен һәм торак йортлар өчен номерларны сатып алу (әзерләү).

- Якты- Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы урнаштыру (материал сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Якты - Күл авылында Бөек Ватан сугышы ветераннары стендын бизәү

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы. Совет ур., 51 йорт.

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Якты- Күл авылы. Якты-Күл, 26 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина